| | |
|---|---|
| БАВЛИНСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29.05.2020 Баулы шәһәре № 132

Татарстан Республикасы Баулы шәһәр
Советының 2019 елның 16 октябрендәге
115 номерлы «Баулы муниципаль
районының «Баулы шәһәре» муниципаль
берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет
процессы турындагы нигезләмәне раслау
хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына казначылык хезмәте күрсәтү һәм казначылык түләүләре системасы өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 27 декабрендәге 479-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Баулы шәһәр Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Баулы шәһәр Советының 2019 елның 16 октябрендәге 115 номерлы «Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына (2019 елның 12 декабрендәге 124 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

12 статьяның 15 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- шәһәр бюджетының бердәм счетыннан күчерелгән акчалар һәм шәһәр бюджетының бердәм счетына күчерелә торган акчалар арасындагы аерма, шәһәр бюджетының бердәм счетында калдыклар белән идарә итү буенча операцияләр үткәргәндә.»;

35 статьяның 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Агымдагы финанс елының соңгы эш көнендә кадәр, шәһәр бюджеты үтәлешенә казначылык хезмәте күрсәтүче орган билгеләнгән тәртиптә Шәһәр бюджетының бердәм счетында калган акчалар чикләрендә бюджет йөкләмәләрен түләргә тиеш.».

2. Әлеге карарны www:pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм www:Bavly.tatarstan.ru адресы буенча Баулы муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы җитәкчесенә йөкләргә.

4. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Баулы шәһәре Мэры,
шәһәр Советы Рәисе

Р.Х. Гатиятуллин